КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 сентябрь г.Казань № 830

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 16 май, 327 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милке хакындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 16 май, 327 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милке хакындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. «Интернет» челтәрендәге сайтта урнаштыру юлы белән таратыла торган Татарстан Республикасы дәүләт милке турындагы мәгълүмат белешмәләрнең түбәндәге исемлеге белән билгеләнә (мондый белешмәләр файдаланылуы закон белән тыела торган мәгълүматларны үз эченә алган очраклардан тыш):

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашкан урыны);

Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләре исемлеге (исеме, урнашкан урыны);

устав капиталы өлешләре (акцияләр пакетлары) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урнашкан урыны, устав капиталында дәүләт өлеше);

Татарстан Республикасы милкендә булган күчемсез мөлкәт (биналар, урыннар) исемлеге (исеме, урнашкан урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, аннан файдалануга чикләү, өченче затлар хокуклары белән чикләү);

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы);

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы дәүләт милке турындагы әлеге мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга мөмкин. ».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин